РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

**№ 34/3** **2018 елның 04 мае**

***Решение*** ***Карар***

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында
муниципаль хезмәт турында»
2008 елның 23 декабрендәге
28/5 номерлы Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Советы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2008 елның 23 декабрендәге 28/5 номерлы карары (Чистай муниципаль районы Советының 2009 елның 08 апрелендәге 30/6 номерлы, 2010 елның 21 маендагы 40/7 номерлы, 2012 елның 16 маендагы 17/9 номерлы, 2012 елның 31 августындагы 20/2 номерлы, 2013 елның 16 июлендәге 27/3 номерлы, 2014 елның 4 апрелендәге 34/4 номерлы, 2015 елның 28 апрелендәге 45/12 номерлы, 2016 елның 20 сентябрендәге 13/1 номерлы, 2017 елның 28 июнендәге 22/2 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяның 1 пунктындагы 10 пунктчасында «- күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 10 ел эчендә, ә күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъектының чакыру комиссиясе карарына карата гражданның күрсәтелгән бәяләмәсенә карата гражданның шикаяте буенча судка шикаять бирелгән булса, - суд карары законлы көченә кергән көннән алып 10 ел эчендә, гражданның хокукларын күрсәтелгән бәяләмә буенча Россия Федерациясенең тиешле субъектының тиешле чакырылыш комиссиясе карар чыгарганда гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә карата хокук бозылмаган дип танылган көннән алып 10 ел дәвамында» сүзләрен өстәргә;

1.2. 14.1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүләр куллану турындагы белешмәләр муниципаль хезмәт узган

җирле үзидарә органы тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.».

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе К.В. Ивановка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов